ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяда:

а) 1 өлештә:

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“18) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;”;

20 пунктта “шул исәптән сатып алу юлы белән,” сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 39 пункт өстәргә:

“39) “Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында” 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнашу.”;

б) 3 өлештә:

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;”;

түбәндәге эчтәлекле 16 – 19 пунктлар өстәргә:

“16) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирлекләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

17) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

18) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

19) җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына теләгәндә керә алуын тәэмин итү дә керә.”;

в) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә шәһәр җирлекләре өчен каралган, әлеге статьяның 3 һәм 4 өлешләре нигезендә авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләр муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре булып тора һәм авыл җирлекләре территорияләрендә тиешле муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителә.”;

2) $15^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

“14) җирлек территориясендә яши торган хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау чараларын күрергә.”;

3) 16 статьяның 1 өлешендә:

а) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14) тиешле муниципаль районнар территорияләрендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю), ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;”;

б) 15 пунктта “, шул исәптән сатып алу юлы белән дә” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $19^3$ пункт өстәргә:

“19) муниципаль район милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру, муниципаль район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау;”;

г) түбәндәге эчтәлекле 35 пункт өстәргә:

“35) “Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында” 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау.”;

4) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“24) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю), ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;”;

б) 26 пунктта “, шул исәптән сатып алу юлы белән” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 43 пункт өстәргә:

“43) “Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында” 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау.”;

5) $17^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле15 пункт өстәргә:

“17) шәһәр округы территориясендә яши торган хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау чараларын күрергә.”;

6) 18 статьяның 1 өлешендә:

а) $6^1$ пунктка “программаларын” сүзеннән соң “, җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын” сүзләрен өстәргә;

б) $8^1$ пунктка “, Россия Федерациясенең мәгариф турында законнарында һәм Россия Федерациясенең муниципаль хезмәт турында законнарында каралган тәртиптә муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне оештыру” сүзләрен өстәргә;

7) 20 статьяга түбәндәге эчтәлектәге $5^1$ өлеш өстәргә:

“$5^1$. Гражданнардан сорашып белешү үткәрүне билгеләү һәм уздыру муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.”;

8) 21 статьяда:

а) 4 өлешнең өченче абзацына “, җирлек башлыгы хәлиткеч тавыш хокукы белән җирлекнең вәкиллекле органы составына керә һәм аның рәисе вәкаләтләрен башкара” сүзләрен өстәргә;

б) 8 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

9) 22 статьяның 10 өлешендә “урындагы зат” сүзләрен “вазыйфаи зат әлеге Законның 24 статьясындагы 4 өлеше нигезендә” сүзләренә алмаштырырга;

10) 23 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

“$4^1$. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарын кабул иткәндә муниципаль берәмлек башлыгы тавышы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.”;

б) 5 өлешнең икенче җөмләсендә “Җирле” сүзен “Әлеге Законның 24 статьясындагы 3 өлешенең 1 пункты яисә 4 өлеше нигезендә җирле” сүзләренә алмаштырырга”;

11) 24 статьяда:

а) 3 өлешнең 2 пунктында “муниципаль берәмлекнең” сүзләре алдыннан “хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән” сүзләрен өстәргә;

б) “Әлеге статьяның 3 өлешендәге 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән чикләүләр” сүзләрен “Әлеге статьяның 3 өлешендәге 3 пунктында билгеләнгән чикләүләр” сүзләренә алмаштырырга;

в) 6 өлешкә “әгәр муниципаль берәмлек башлыгы” сүзләреннән соң “әлеге статьяның 3 өлешендәге 1 пункты яисә 4 өлеше нигезендә” сүзләрен өстәргә;

12) 26 статьяның 1 өлешендәге икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Әлеге Законның 24 статьясындагы 3 өлешенең 1 пунктында һәм 4 өлешендә каралган очракларда муниципаль берәмлек башлыгы җирле администрация башлыгы булып тора. Башка очракларда җирле администрация башлыгы муниципаль берәмлек уставында билгеләнгән вәкаләтләр чорына җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча төзелә торган контракт буенча шушы вазыйфага билгеләнеп куелган зат була.”.

13) 29 статьяда:

а) “Җирле үзидарә” сүзләрен “1. Җирле үзидарә” сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

“2. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләре срогы муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм ике елдан кимрәк, биш елдан артыграк була алмый.”;

14) 33 статьяның 6 өлешендәге беренче абзацында “аларны акчалата тотуга факттагы чыгымнарын” сүзләрен “аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнарны” сүзләренә алмаштырырга;

15) 39 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“39 статья. **Шәһәр һәм авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү**

Шәһәр һәм авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләү Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

16) 40 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“40 статья. **Муниципаль районнарның, шәһәр округларының бюджет тәэмин ителешен тигезләү**

Муниципаль районнарның, шәһәр округларының бюджет тәэмин ителешен тигезләү Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, аның 1 статьясындагы 1 пунктының “а” пунктчасындагы икенче һәм өченче абзацларыннан, “б” пунктчасыннан, 3 пунктындагы “а” һәм “в” пунктчаларыннан, 4 пунктындагы “а” пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының “а” пунктчасындагы икенче һәм өченче абзацлары, “б” пунктчасы, 3 пунктындагы “а” һәм “в” пунктчалары, 4 пунктындагы “а” пунктчасы 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казан,Кремль
2015 елның 21 июле
№ 59-ТРЗ